Республика Татарстан
Совет Новоимянского
сельского поселения
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге
Советы

РЕШЕНИЕ
17 июнь 2020 ел

КАРАР
№ 11

**IV чакырылыш Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Яңа Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2007 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлегенең 12 статьясы нигезендә, «Яңа Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар бирде:

1. IV чакырылыш Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Яңа Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны җирлекнең торак пунктларының рәсми стендларында, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

«Яңа Имән авыл җирлеге»
МБ Советы рәисе Р.Ф.Гараев